КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 июль г.Казань № 590

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турында» 2012 ел, 10 август, 676 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 июль, 528 нче; 2013 ел, 5 август, 548 нче; 2014 ел, 15 март, 156 нчы; 2014 ел, 29 ноябрь, 929 нчы; 2015 ел, 30 апрель, 308 нче; 2015 ел, 2 сентябрь, 632 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 815 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 741 нче; 2016 ел, 31 октябрь, 802 нче; 2017 ел, 20 июнь, 394 нче; 2017 ел, 2 ноябрь, 839 нчы; 2018 ел, 12 сентябрь, 771 нче; 2019 ел, 22 март, 207 нче; 2020 ел, 30 май, 441 нче; 2020 ел, 14 декабрь, 1135 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының дәүләт заказчысы һәм операторы итеп билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турындагы нигезләмәнең 2 бүлегендәге унҗиденче абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык си-

стемасын оештыру турында» 2013 ел, 27 август, 603 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 18 июнь, 419 нчы; 2014 ел, 16 декабрь, 990 нчы; 2015 ел, 2 апрель, 207 нче; 2018 ел, 24 август, 707 нче; 2020 ел, 30 май, 441 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

«Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен дәүләт заказчысы һәм техник операторы итеп;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын Системаның функциональ администраторы итеп.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2014 ел, 9 июль, 479 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 май, 441 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

«Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен «Халык инспекторы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының дәүләт заказчысы һәм операторы итеп»;

«Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасын Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат үзәге – мәгълүмат системасының ярдәмче системасы итеп.»;

әлеге карар белән расланган «Халык инспекторы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәнең 2 бүлегендәге тугызынчы абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүне оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1319 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүне оештыру һәм үткәрү тәртибендә:

2 бүлекнең унынчы абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, Бәяләү критерийларын, Бәяләү шкаласын карап тикшерә һәм килештерә һәм аларны, Җаваплы орган һәм Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, беркетмә белән раслый;»;

4.2 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле турында» 2019 ел, 25 октябрь, 956 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 23 сентябрь, 859 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесен» сүзләрен «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле тәртибендә 1 бүлекнең 1.2 пунктындагы сигезенче абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                            А.В.Песошин